КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 11 февраль г.Казань № 97

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында” 2017 ел, 26 апрель, 252 нче карары белән расланган Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында” 2017 ел, 26 апрель, 252 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 14 июнь, 479 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан Г.Р.Нигъмәтуллинаны, А.А.Фоминны чыгарырга;
комиссия составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча) |
| Низамова Ләйсән Гаптелхан кызын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү һәм мәдәният идарәсе башлыгын, комиссия секретарен |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәитгәрәй улын | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесен; |

Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча)»;

Зарипов Айрат Ринат улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин